| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 15.11.2022 | Казан ш. | № 407-123/кс-2022 |

«Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» акционерлык җәмгыятенең «Спас» филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2023 елга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» акционерлык җәмгыятенең «Спас» филиалы (алга таба – «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» АҖ «Спас» филиалы) өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга шушы карар кушымтасына ярашлы рәвештә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм

энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» АҖ «Спас» филиалына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» акционерлык җәмгыятенең «Спас» филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 01.12.2021 № 425-113/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 №407-123/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» АҖ «Спас» филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2023 елга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Спас муниципаль районы | | |
| 1 | «Татарстан Республикасы инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне сак куллану технологияләрен үстерү идарәсе» АҖ «Спас» филиалы | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 46,25 | 31,31 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 38,54 | 26,09 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге